

Кешеләр нинди сорт орлык бәрәнгесе ала, орлык суганы ничә сум икәнен белдем.
Яз башынын салкын коннәреннән сон, жылылар китте, тагы салкынайтты, тагы жылытты: бакчачылык сезонын ачып жибәрделәр инде. Ә бит бакчачынын мәшәкатьләре ифрат квп. Орлык, утыртырга vсентеләр сатып алудан башлап, корәк белән тырма шикелле кирәк-яраклар әзерләvгә кадәр.
Жир казудан алда орлыклар сатып алу, помидор-кыяр, чәчәкләр vсентеләре vстерv этапларын vтәргә кирәк. Үсентеләребезне январь-февральдә утырткан булсак, хәзер суган орлыгын сатып алу белән шогыльләнәбез. Саранск башкалабыз базарларынын сәvдә рәтләрендә торлесеннән орлык суганы, бәрәнгесен сатучылар квп.       - Быел орлык суганынын килосы уртача 200-350 сумга кадәр. Сортына карап хакы да, - ди базарда сатучы фотодагы Альфия Мангутова.
Ә “Сад-огород” кибетләрендә суганнын килосы 500-700 сум булырга момкин. Мәсәлән, чит илнекеләре. Нинди орлык суганын утыртсан да уныш алып була. Озынчасы да, кызыл «Кармен» суганы да популярлашып китте  – салатлар очен нык әйбәт! Пирогларга да бара. Ул 300 сумнан. Хәзерге вакытта сатып алучыларнын ихтыяжлары торлечә - «Стурон», «Штутгартен», «Бессоновский»ларны да яхшы алалар. Шуны әйтеп китәргә кирәк, суганны диаметры 3 см арткaны стрелкалар жибәрә, шуна кврә суганнын зурлыгын чамалап алырга кирәк. Исегездән чыгармагыз, тунган, яки нык эшегән суган орлыгы шулай ук стрелкалар жибәрә. Тагы чәчv вакыты да, унышны мул алыйм дисән, һаванын жылы вакытында, 5нче майдан сон утырту яхшырак. Мәсәлән, 2025 елнын Айлы календаре буенча суганны утырту очен унышлы коннәр - 2, 3, 6, 7, 8, 11, 12, 13 һәм 14 май, дип язылган.
Орлык бәрәнгесенен килосы 80-100 һәм аннан артык сумнан иде. Кvпләр кин билгеле “Гала” сортын яратып ала. Бәрәнгеләре саргылт тостә. Үзем шул сортны да бераз

утыртам: бәрәнге боламыгы-пюре ясарга яхшы. Вак, димәс идем. Авыл халкы бәрәнгене урталай ярып та утырта. Тагы бәрәнгенен иртә олгереп озак кышка саклана торганнарын бакчачылар яратып vстерә. Бу очракта сортларнын санап бетергесез кvп икәнен искә алып, берничәсен санап китәм: “Синеглазка”, “Невский”, “Розара”, “Надежда Айт”, “Левада”, “Довира”, “Жигулевский”, “Накра”, “Тимо Ханккиян”...
Базарчылар vзләре әйтvенчә, тиздән рассадалар да тулы ассортиментта сатуга чыгачак. Кәбестә, томат vсентеләре сатуда бар инде. Ә менә кыярны кvпләр коннәр жылыткач, ачык грунтка гына утырту яклы булып чыкты. Менә кәбестә рассадаларын елнын-елында халык котеп ала икән. Сатып алучылар кvбрәк чәчәк vсентеләре һәм куаклар белән кызыксына. Чәчкә рассадаларыннан петуния, вио-лалар һәм тагы кvп торлесе сатуда бар.
Әлеге вакытта бакчачылар ни эшли сон? Беренче чиратта кортларга каршы корәшәләр. Медный купарос, “Бордосская жидкость” һәм башкаларын агачлар белән куакларга сиптерәләр. Агач-ларыбыз чәчәк атканчы сибәргә олгерделәр.
Туфрак дымлы чакта, бакчага азотлы ашламалар керттек. Ашлама дигәндә, мочевина, аммиак селитрасы, тирес сыекчасы кебекләрен сибәбез. Ашлама – мул һәм сыйфатлы бакча унышына нигез салу. Май бәйрәмнәрендә бәрәнгеләребезне дә утыртырбыз дип уйлыйм; елдан-ел иртәрәк утырта башладык.
Унышларыгыз мул булсын, хормәтле бакчачыларыбыз!

**Наилә НАСЫРОВА**